ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 22 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында” 2016 елның 21 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2016, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 2 өлешендәге 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“9) индустриаль (сәнәгать) паркларга, индустриаль (сәнәгать) паркларның идарәче компанияләренә, сәнәгать кластерларына, сәнәгать кластерларының махсуслаштырылган оешмаларына әлеге Законда һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән кызыксындыру чараларын куллану максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан өстәмә таләпләр куелган очракта, шушы индустрия (сәнәгать) паркларының, индустрия (сәнәгать) парклары идарәче компанияләренең, сәнәгать кластерларының, сәнәгать кластерлары махсуслаштырылган оешмаларының бу таләпләргә туры килүен раслый;”;

2) 12 статьяда:
а) 2 өлештә “билгеләнә” сүзен “билгеләнергә мөмкин” сүзләренә алмаштырырга;
б) 3 өлештә “Индустриаль (сәнәгать) паркның һәм индустриаль (сәнәгать) паркның идарәче компаниясенең индустриаль (сәнәгать) паркка, индустриаль (сәнәгать) паркның идарәче компаниясенә карата Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән таләпләргә” сүзләрен “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан индустриаль (сәнәгать) паркка,

индустриаль (сәнәгать) паркның идарәче компаниясенә карата таләпләр билгеләнгән очракта, индустриаль (сәнәгать) паркның һәм индустриаль (сәнәгать) паркның идарәче компаниясенең бу таләпләргә” сүзләренә алмаштырырга;

3) 13 статьяда:

а) 1 өлештә “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән өстәмә таләпләргә” сүзләрен “, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан өстәмә таләпләр билгеләнгән очракта, аларга” сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә “Сәнәгать кластерының һәм сәнәгать кластерының махсуслаштырылган оешмасының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән өстәмә таләпләргә” сүзләрен “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан өстәмә таләпләр билгеләнгән очракта, сәнәгать кластерының һәм сәнәгать кластерының махсуслаштырылган оешмасының аларга” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 05 июль
№ 47-ТРЗ